Тукай образын үзәккә алган әдәбият гомумәдәби процесстагы тенденцияләргә аваздаш үсеш-үзгәреш кичерә. Мәгълүм булганча, XX йөз башы әдәби-эстетик фикер үсешендә һәм иҗтимагый-мәдәни тормышта кискен үзгәрешләр чоры, бер үсеш баскычыннан башка этапка күчү дәвере, чиктәш ситуациягә аяк басу вакыты буларак билгеләнә. Сүз сәнгате, бер яктан, үткән гасырлар сынавын кичкән классик традицияләргә нигезләнүен дәвам итсә, икенче яктан, шул традицияләрне «үтеп китеп», аларны яңарту, трансформацияләү омтылышын алга куя. Милли яңарыш һәм үсеш идеяләре әдәбият, мәдәният, мәгариф өлкәләрендә үзгәреш, яңача сулыш кирәклеген аңлау белән бергә үрелә. Билгеле бер кануннар нигезендә формалашып, аң-белемгә өндәгән, шул юл белән халыкны бәхетле итәргә омтылган мәгърифәтчелеккә алмашка иҗтимагый-сәяси тормыш белән тирән бәйләнгән, милли идея белән сугарылган әдәбият килә һәм милли хәрәкәт халыкны яңа тормышка әйдәү идеясе белән бәйләнә. Идеаль тормыш моделен төзеп, идеаль герой-тип тудырып, шушы максатка ирешеп була дип санала [2: 194]. Шушы шартларда тормыш юлында кыйбласын югалтканнарга үрнәк булырлык, милләтнең рухи ихтыяҗын канәгатьләндерерлек шәхесне идеал итү, эзләү һәм табу зарурияте туа, әдәби-эстетик фикердә чор таләпләренә җавап бирердәй идеаль шәхес мәсьәләсендә эзләнүләр башлана һәм, мондый югарылыкка ирешкән шәхес буларак, Тукай аерып куела.

Тукай образында чагылыш тапкан әлеге идеал әдәби мәйданга, урта гасыр мөселман һәм XIX гасыр традицияләрен дәвам итеп, рус, көнбатыш фәлсәфәсенең эстетик фикерләре белән баетылган, чорга аваздаш яңа дөньяви үрнәк булып килә. XX йөз башы иҗтимагый-фәлсәфи һәм әдәби фикерендә алга куелган ике үзенчәлек –дөньявилыкка йөз белән борылу һәм милли фактор – аның формалашуына тирән йогынты ясый, чорның төп сыйфатларына таянып, без аны «милли идеал» дип атыйбыз. Шулай татар әдәбияты Шәрыктан Гаребкә, дини-мәгърифәтчел рухтан – дөньяви реалистик һәм романтик, традицион халык мәдәниятеннән югары культурага борылган вакытта сүз сәнгатендә яңа идеал – шагыйрь, замандаш милләт хадиме образы пәйда була. Аның нигезен И.Гаспралы тәкъдим итә, соңрак бу фикерләр Г.Баруди тарафыннан үстерелә һәм «милләт хадиме» милләт бәхете өчен көрәшү»че [3: 36] буларак шәрехләнә башлый, Й.Акчура милләт хадименең «милләт сулышы белән яшәүче рухи юлбашчы, бөтендөнья фикер үсешендәге яңалыкларны үз милләте файдасына хезмәт иттерүче» [4: 11] дип төгәлләштерә. Әнә шулай «XIX гасыр ахыры җәдитчелек фәлсәфи фикерендәге герой концепциясе» [5: 29] XX йөз башында җиңеп чыга. Алга таба әлеге концепция Н.Хәлфин, Җ.Вәлиди, Г.Зәбирев хезмәтләрендә тагын да камилләшә, мәсәлән, Г.Зәбирев Г.Ибраһимовның «Яшь йөрәкләр» романына язган рецензиясендә милли идеалның милләт үсешендәге әһәмиятен ассызыклап үтә [6: 313].

XX гасыр башы татар поэзиясендә Г.Тукай, шушы таләпләргә җавап биреп, милләткә хезмәт итү, милләт бәхете өчен көрәшү кебек сыйфатларны үзендә туплаган милли идеал буларак күтәрелә, ул татарны милләт буларак туплауда бер үзәккә әйләнә.

XX йөз башы татар шигъриятендә Тукай образының поэтик гәүдәләнешендә дини-

суфичыл Камил инсан концепциясенең һәм рус, аның аша Аурупа әдәбиятыннан кергән «гадәттән тыш кеше» теориясенең синтезы күренә. Бер яктан, көнчыгыш суфичылык әдәбиятыннан үтеп кереп, урта гасыр татар сүз сәнгатендә иркен файдаланылган Камил инсан өйрәтүе үзләштерелүен дәвам итә. Билгеле булганча, суфичылык фәлсәфәсенең нигезләрен эшләгән галим Мөхии-д-дин Ибн Гарәби (1165-1240) тарафыннан тәкъдим ителгән [7: 63] Камил инсан Аллаһның кешедәге иң төгәл, дөрес чагылышы буларак карала. Шәрык фикер иясе тарафыннан абсолют камиллек үрнәге итеп Адәмнән Мөхәммәдкә кадәрге пәйгамбәрләр күтәрелә, соңгысына аеруча игътибар бирелә. Мөхәммәд галәйһиссәлам суфиларның идеалы төсендә билгеләнә, алар пәйгамбәр кебек үк, Аллаһының рухы һәм сыйфатлары белән сугарылган камил шәхес – «инсануль-камил» дәрәҗәсенә ирешү турында хыялланалар» [8: 13] һәм Аллаһ бөеклегенә күтәрелеп, аның белән тиңләшкән камил кеше бөеклек (возвышенное) буларак кабул ителә [9: 57]. Шулай Мөхәммәд пәйгамбәр мөселман дөньясының идеалына әверелә, классик көнчыгыш поэзиясендә аңа багышлап махсус шигырьләр – Нәгът-и шәрифләр дә иҗат ителә. Әлеге принциплар Тукайны әдәби гәүдәләндерүдә дә ачык чагыла һәм аның башлангычы көнчыгыш суфичылык поэзиясенә тоташуы бәхәссез [10: 23].

Икенче яктан, Ф.Ницшеның шушы чорда Аурупа әдәбиятыннан үтеп кергән һәм билгеле күләмдә татар дөньясында яңгыраш тапкан «гадәттән тыш кеше» [11: 60] өйрәтүе дә Тукай образында чагылыш тапкан милли идеалның әдәби гәүдәләнешенә тәэсир ясый. Ницше, Иранда туган зароастризм диненең пәйгамбәре Заратустра нигезендә, «Аурупа цивилизациясе күрмәгән яңа гений, яңа Кеше образын тудыра» [12: 178]. Ул «өстен кеше»нең, җәмгыять кануннарына буйсынып яшәүдән бигрәк, башкалар өчен азат шәхес үрнәге булырга тиешлеген билгели. Шул чордагы татар әдәби фикеренең ихтыяҗларына өлешчә җавап биргән әлеге фәлсәфи тәгълимат милләт азатлыгына омтылган, шул нигездә яңа яшәеш моделен, җәмгыятен төзергә теләгән татар зыялылары өчен мөһим тоела, милли эчтәлеккә утыртылып, сүз сәнгатенә «көчә» һәм милли идеалның гражданлык характерында урын ала.

XX йөз башында әлеге нәзари нигезгә таянып иҗат ителгән бер төркем шигырьләрдә Тукайны пәйгамбәр образы белән бәйләнештә сурәтләү тенденциясе чагыла. Шагыйрьлекне пәйгамбәр миссиясе белән тиңләп карау тенденциясе пантеистик юнәлештәге суфичылык әдәбиятыннан ук килә. Илаһи сүзнең зур кыйммәткә ия булуы, гомумән, урта гасыр әдәби фикерендә канун санала. Ю.Лотман бу үзгәрешләрнең рус әдәбиятында XVIII гасырда башлануын һәм поэзия, шигъри сүзнең илаһи текстларга алмашка килүен һәм аларның функцияләрен үзләштерүен, илаһи сүзне халыкка җиткерүче пәйгамбәр урынын шагыйрь шәхесе алуын ачыклый [13: 122]. Әдәби-эстетик фикер татар җирлегендә дә шул рәвешле секуляризация, сыйфат үзгәреше кичерә. Илаһи сүз дөньяви фикер белән алышына торган бу чорда, дини идеология башкарак планга күчеп, аның урынын иҗади сүз ала һәм дөньяви идеология, әдәби-эстетик, фәлсәфи фикернең төп таянычына әйләнә. Бу фикерләрне дәлилләп, Г.Ибраһимов «Альбом мөнәсәбәте илә» мәкаләсендә: «Сәнгать – яңа заманның дине, бөек сәнгатькярләр ул диннең пәйгамбәрләредер» [14: 200], – дип яза. Шуңа да 1910 еллар татар поэзиясендә, шагыйрь һәм шагыйрьлек темасына бәйләнештә, пәйгамбәр – шагыйрь образы алга чыгуы [15: 122] табигый.

С.Сүнчәләйнең «Азан» (1912), «Шагыйрьгә» (1913), Н.Габидовның «Нигә бу шәмнәр сүнә» (1913) шигырьләрендә Тукай ак, чиста күңелле, рухи саф, әхлакый бөтенлеккә ия, сабыр, акыллы шагыйрь – пәйгамбәр – дәрәҗәсендә сурәтләнә. Сүнчәләй иҗатын өйрәнгән Р.Мусабекова «Азан» да (1912) азан символик образын «яңа таң»ны хәбәр итүче, рухи коллыктан, торгынлыктан уятучы» [16: 38] дип шәрехли. Моннан тыш, символик образ буларак, шигырь тукымасында аның башка мәгънә бөтенлекләренә ия булуы да ачык күренә. Шигырь авторы, Тукайның һәр сүзен Аллаһ сүзе, бөтен иҗатын «татар халкын – баен, ярлы гавамын, мулласын» йокыдан уятучы, «таң атуын хәбәр итүче» азан белән тиңләштереп, шагыйрьне Аллаһ югарылыгына күтәрә, Аллаһ – кеше, кеше – Аллаһ кебек суфичылык мотивы тудырыла:

*Бер гаҗәпләнсен кояш, таң, җен, фәрештә, җир, адәм,*

*Бар да торсын мактасын тәңрен, яраткан Алласын!* [17]

Биредә «камил инсан» өйрәтүенең әйләнмә (круг кругов) образы кулланылышка керә һәм сурәт иҗат итүнең үзенчәлекле алымына әйләнә. С.Сүнчәләй тирә-яктагыларны «кояш, таң, җен, фәрештә, җир, адәмнәр»гә

тиңләштереп, үзгә бер дөньяны бирә һәм Тукайны шуның үзәгенә куя. Әмма әлеге югарылык суфичылык чикләрендә түгел, дөньяви контекстта кабул ителә, шигърияттнең бөеклеге кебек кабул ителеп, шигъри даһи – «Аллаһ» янәшәлеге тудырыла: Тукай шигъриятне һәм милләтне яшәтүче, алга әйдәүче үзәк бер көчкә әверелә, милли рухлы иҗаты шуңа ирешүдә төп корал хезмәтен үти. С.Сүнчәләйнең «Шагыйрьгә» (1913) шигырендә дә пәйгамбәр-вәхи янәшәлеге Тукай-шигырь янәшәлеге булып төгәлләшә, автор аның шигырьләрен вәхи, Аллаһтан иңгән кәләмнәргә тиңләп, шәхесен Аллаһ кәләмнәрен Җир кешеләренә тапшырып, халыкны сабырлыкка өндәүче изге пәйгамбәр дәрәҗәсендә сурәтли.

Х.Габидовның фәлсәфи рухта язылган «Нигә бу шәмнәр сүнә» (1913) шигырендә Тукай образы суфичылык әдәбиятында еш кулланылган шәм символы аша ачыла. Суфичыл образлар системасы, диңгез шаулавы, бөтен дөньяның төтенгә күмелүе, куркыныч өннәр чыгарып, ил корабының ыңгырашуы кебек романтик детальләр ярдәмендә шагыйрь татар милләтенең торышын бәяли, шагыйрь һәм милләт язмышын илаһи бердәмлектә сурәтләргә омтыла. Суфи әдәбиятта Аллаһ сурәтендә кулланылган шәм, традицион эчтәлеген үзгәртеп, Тукайның даһилыгын, бөеклеген ачуга юнәлтелә, суфичыл образлар төп идеяне төгәлләштерә: татар милләтен даһилары яшәтә, аларның үлеме милләтнең якты киләчәген томанлый. Ш.Бабичның «Габдулла әфәнде Тукаев» (1911), «Тукай үлгәч» (1913) кебек мәдхия-мәрсияләре дә Тукайны пәйгамбәр, камил инсан дәрәҗәсендә тасвирлый. Әнә шулай шагыйрь образын пәйгамбәр баскычына кую әдәбиятның иҗтимагый дәрәҗәсен күтәрә, шагыйрьлекне милләт өчен иң әһәмиятле, файдалы эшчәнлек төренең берсе итеп аңлата башлый.

Шуңа параллель рәвештә Тукай иҗатының бөеклеге, даһилыгы турында уйланулар алга чыга. Шагыйрьнең вакытсыз үлеме бу процессны тизләтеп җибәрә, ул татар халкы өчен зур югалту буларак кабул ителә. Тукайга багышланган бер төркем шигырьләр менә шушы шартларда киң мәйдан ала, шагыйрьгә багышлап, илледән артык шигырь иҗат ителә. Мәсәлән, С.Сүнчәләйнең «Иңеш» (1913) шигыре – шушы юнәлештәге әсәрләрдән. Кояш образының шигырь структурасында динамик хәрәкәте, үсеш-үзгәреше аркылы автор Тукай шәхесенә, тормышына һәм татар халкының шагыйрьне югалтканнан соңгы халәтенә бәя бирә. Шушы ук мотив Ш.Фидаиның «Тукай» (1913), М.Укмасиның «Тукайны сагыну» (1913) шигырьләрендә тагын кабатлана.

Г.Ибраһимовның 1913 елда дөнья күргән «Татар шагыйрьләре» (1913) хезмәтенә мөнәсәбәтле, Тукай иҗаты тирәсендә башланган әдәби бәхәсләр тәэсирендә аның шагыйрьлек кыйммәтенә, даһилыгына бәя тагын да калкулана: ул татар реалистик поэзиясен нигезләүче шагыйрь, остаз, тел остасы үрнәге итеп куела башлый. Бу юнәлештә С.Сүнчәләй беренчеләрдән була. Аның «Бер газетага» (1913) шигыре төп мәгънәсе белән шул чорда Тукайга каршы юнәлтелгән урынсыз карашларга, шагыйрь һәм халык мәсьәләсе тирәсендә барган бәхәсләргә җавап рәвешен ала. Җ.Юмаевның «Шагыйрь үлде» (1913) шигырендә дә шушы мотивлар алга куела. Автор Тукай өстенә «гайбәт яудырган» тәнкыйтьчеләрне «монафикълар, бәдбәхетләр» дип атый һәм шагыйрьнең үлемен «шул ходайсызлардан» котылуның бердәнбер чарасы итеп күрә. Г.Сөнгатинең «Сүнде» (1914), Я.Мамишевның «Ядкяр өчен» (1913), К.Патииның «Тукайга» (1914) шигырьләрендә дә Тукайның шагыйранә бөеклеген ачу тенденциясе күзәтелә.

Р.Ибраһимованың «Китте шагыйрь» (1913), Я.Кизләвинең «Сөекле шагыйремез мәрхүм Г.Тукаев рухына» (1913), Г.Гайнуллин-Чокалыйның «Габдулла әфәнде Тукаев хакында мәрсия» (1913) шигырьләрендә исә Тукай халыкчы буларак гәүдәләнеш таба. Чор әдәби фикеренә аваздаш төстә, халыкчылык төшенчәсе «идея байлыгы, идеалы күпчелекне эченә алган халык мәнфәгатенә хезмәт итү» [18: 83], «гавам мәнфәгатен алга кую, фәнне, сәнгатьне гавамлаштырырга хезмәт итү» [19] мәгънәсендә аңланыла.

Тукайга багышланган поэзиядә шагыйрь шәхесе, иҗатына хас төп сыйфатлар еш кына шартлы сурәтлелек аша ачыла, шушы фонда шигъри фикерләүдә символика алга чыга. Мәсәлән, Ш.Бабичның «Габдулла әфәнде Тукаев» (1911) шигырендә Тукай ай образы, К.Курмашевның «Әдәбият былбылы олугъ шагыйремез Габдулла Тукаевка» (1913) әсәрендә Чулпан, якты кояш образлары аша бәяләнә. Кояш, Ай, Чулпан йолдыз образ-символлары белән Тукайның берлеге, бөеклеге, поэзиясенең зурлыгы һәм аны югалткан халык фаҗигасе арасында үткәрелгән параллельләр

шагыйрьнең милли кыйммәтен көчәйтүгә хезмәт итә. Бу төр шигырьләрдә Тукайга соклану, аңа булган чиксез мәхәббәт, шагыйрь иҗатының бөеклеген исбатлау төп эчтәлекне тәшкил итә. Лирик герой өчен Тукай остаз, чиксез бөеклек, шагыйранә талант үрнәге булып күтәрелә.

Шагыйрь иҗатының миллилеген, лирик нәфислеген бәяләүгә юнәлтелгән шигырьләрдә дә символик сурәтлелекнең көчле булуы күзгә ташлана. Мәсәлән, Г.Сөнгатинең «Милләтебезнең сандугачы китте» (1913), М.Фәйзинең «Габдулла әфәнде!» (1912) шигырьләре – шушы юнәлештәге әсәрләрдән. Мондый шигъри әсәрләрдә Тукай иҗатын бәяләү юлында суфичылык әдәбиятыннан ук яратып кулланылган бакча һәм сандугач символик образлары активлаша. Шагыйрь образын сандугач символы аша чагылдыру тенденциясе көнчыгыш әдәбиятында ук киң кулланыла һәм үз эченә бикләнгән, шау-шулы халык дөньясыннан яшеренгән шагыйрьне гәүдәләндерә, ләкин Г.Сөнгати, М.Фәйзи әсәрләрендә аның башка мәгънәви бөтенлеге күзәтелә: сандугач символы Тукай поэзиясенең камиллеген, серлелеген, милләткә мәхәббәтен ачуга юнәлтелә, Тукай – милләт сандугачы янәшәлеге барлыкка килә.

Гомумән, тикшерелә торган чор лирикасында шагыйрьне объектив сурәтләүдән бигрәк, субъектив башлангычка зур урын бирелә, Тукай үлеменә бәйле рәвештә халыкның эчке дөньясын, җанындагы сызлануларын, рухи кичерешләрен чагылдыру өстен куела һәм романтик сурәтлелек, экзистенциаль мотивлар алга чыга. Романтик буяулар шагыйрьнең бөеклеген, халыкның аңа чиксез мәхәббәтен һәм хөрмәтен күрсәтүгә, Тукайның татар дөньясына багышлаган гомерен, хезмәтләрен бәяләүгә йөз тота, экзистенциаль мотивлар исә милләтнең аны югалтканнан соңгы халәтен ачуга юнәлдерелә.

1920-1950 еллар – Тукай турындагы әдәбиятта аның шәхесен үзәккә алган шигъри әсәрләрнең чагыштырмача аз язылган чоры. Шушы вакыт аралыгында бер-бер артлы килгән Октябрь инкыйлабы, гражданнар, Бөек Ватан сугышлары кебек вакыйгалар Тукай турындагы әдәбиятка да сизелерлек йогынты ясый, шулай да Тукай шәхесенә, образына игътибар тулысынча кимеми. Мәсәлән, 1923 елда «Тукайның үлүенә ун ел тулу хатирәсенә багышлап» исемендә күмәк басма дөнья күрә, Ф.Бурнаш «Көрәш җырлары» (1923) бер җыентык бастыра, ләкин ул мәҗмугада Тукайга яд ителгән шигырьләр урын алмый, Ш.Бабич, Н.Исәнбәт, К.Әмири, З.Бәширова, Һ.Такташ, К.Нәҗми, М.Җәлил кебек замандашлары яки яшь шагыйрьләрнең «көрәш очкыннары» белән тулы шигырьләреннән үрнәкләр бирелә. Шагыйрьнең үлеменә егерме, утыз ел тулган көннәр дә чагыштырмача тыныч үтеп китә.

Чор әдәби-эстетик фикерендә Гали Рәхим ике карашны аерып чыгарып, болай дип яза: «... әдәбият тарихына ике төрле караш бар: 1) әдәбиятка нәфис сәнгать итеп кенә карау (эстетизм); 2) әдәбиятның иҗтимагый әһәмиятенә игътибар итү (социологизм)» [20: 287]. Мондый күренеш Тукай турындагы әдәбиятта да ачык чагылыш таба: шуның нәтиҗәсендә яңа алымнар эзләү әдәби фикердә социологизм белән эстетик фикернең эчке көрәшенә китерә.

Илдәге яңарышны яклаган, шул көрәштә үзен аямаган уңай каһарманны сурәтләү көн үзәгенә баскан чорда Г.Тукай образының да пролетариат билгеләгән төп сыйфатлар, таләпләр яссылыгыннан бәяләнергә тиешлеге көн тәртибенә куела һәм бер төркем шигырьләрдә аның сурәтләнеше пролетар, социаль эчтәлек белән бәйләнә. Шуңа мөнәсәбәттә аны «түбән сыйныф» азатлыгын «яклап көрәшкән» шагыйрь, патриот, ягъни «безнеке» итеп тәкъдим итү тенденциясе формалаша. Тукайның шигърияте дә шул структураның бер буыны итеп карала һәм азатлык өчен көрәш символы булып күтәрелә, сәяси идеалларга буйсындырыла, шигырьләренең иҗтимагый ягына, халыкчанлыгына басым ясала. Мәсәлән, Г.Хуҗиның «Габдулла Тукай истәлегенә» (1938), Ә.Юнысның «Тукайга» (1938), Ш.Маннурның «Җыр мәңгелек» (1938) шигырьләрендә Тукай образы ярлылар өчен көрәшү, азатлык яулау, байларны җиңү мотивлары белән берлектә тасвирлана, шагыйрь һәм халыкны яңа тормышка алып баручы янәшәлеге алга чыга. Мондый үрнәкләрдә, кагыйдә буларак, хәзерге тормышны үткән аша чагылдыру принцибы алга чыга, структур яктан вакытлар оппозициясе көчле. Вакыт бүленеше идея-эчтәлекне ачуда әһәмиятле өлешкә әверелә, вакыт аралыгы, ике чор каршылыгы иҗтимагый эчтәлеккә төреп тәкъдим ителә. Үткән тормыш катып калган, схоластик бербөтен булып, яңа төзелгән җәмгыятьнең алсу, матур көнитешенә каршы куела. Шушы

җирлектә Тукай шәхесе «азат» яшәешкә алып чыгучы образ буларак күтәрелә һәм мондый каршылык Тукай образын социаль бәяләүдә төп сәнгати алымга әверелә.

С.Хәкимнең «Пар ат» (1938-1939), «Шагыйрьнең балачагы» (1940), Г.Шәрәфнең «Шүрәле белән очрашу» (1938) кебек әсәрләре иҗтимагый якның эстетик калып белән алышынуын хәбәр итә. Мондый әсәрләрдә каләм иясе матурлык тудыручы оста, эстетик камил әсәрләр иҗат итүче шагыйрь итеп бәяләнә. Бу тенденция әдәбиятта иҗтимагый якның яктыртылышын гына таләп иткән идеологиягә тискәре мөнәсәбәтне белдерү чарасына да әверелеп китә, әкренләп сәнгатьнең вазифалары, сафлыгы, эстетикасы турындагы сүзгә бару да тоемлана башлый. Нәкъ шушы сыйфатлар Тукай турындагы поэзиядә XX гасырның икенче яртысында булачак үсеш-үзгәрешне нигезли.

Тукай хакындагы поэзиядә яңарыш, иҗтимагый яшәештәге үзгәрешләр тәэсирендә, 1960 елларның икенче яртысыннан башлана, татар әдәбиятының киңәю-тармаклану вакытында яңа сыйфат үзгәрешләре белән байый, тулылана. Аның, алдагы чорлар белән чагыштырганда, башкарак юнәлештә үсеп китүе фәлсәфи һәм әдәби фикердәге яңалыклар, әдәбиятның иҗтимагый кануннарны алга куйган идеологик кысалардан чыгуга омтылышы, дөньяны, яшәешне сәнгатьчә кабул итүнең яңа яклары ачылу белән аңлатыла.

Шушы чордан Тукай образының сурәтләнеше катлаулы һәм катнаш төс ала: бер әсәр чигендә Тукай образына мөнәсәбәттә шагыйрь һәм шигъриятнең хәле, реалистик, романтик һәм мифологик традицияләрнең бергә кушылуы күзәтелә, моңа исә төрле сәнгати алымнар аша ирешелә.

Агымдагы чорда Тукайга багышланган поэзиядәге яңарышны «Тукай тавышын эзләгәндә» (1953), «Халык төсе» (1958), «Без һаман бергә» (1959), «Язгы авазлар» (1966), «Тукайлардан килгән күпердә» (1968), «Чәчәкләр китерегез Тукайга» (1966), «Кулын канга батырса да» (1966) кебек әсәрләре белән Х.Туфан хәбәр итә. Аның шигырьләрендә яңа бер күренеш – Тукайны сурәтләүдәге социологик юнәлеш кире кагылып, иҗтимагый-әдәби эчтәлекне берләштерү сыйфаты беренче планга чыга. Мәсәлән, «Без һаман бергә» (1959) шигырендә ул, шагыйрь һәм дәүләт эшлеклесен чагыштырып, беренчесенең чын юлбашчы икәнлеген раслый, шуның ярдәмендә әдәбиятның тормыш-яшәештәге урынын хакимият баскычыннан да югары күтәрү максатын куя. Хакимнәрдән өстен Тукай образын бизәүдә сакральләштерү, изгеләштерү тенденциясе тоемлана. 1960-80 еллар арасында бу сыйфат шагыйрьгә бәя бирүнең төп хасиятләреннән берсенә әверелә. Моннан тыш, Тукай турындагы поэтик әсәрләрдә «1960-1980 еллар татар шигъриятен тамырдан үзгәртерлек яңалык булып яңгыраган» [21: 120] эзоп теле алымы активлаша. Х.Туфан шигырьләрендә бәя ике яклы төс ала: бердән, аның шагыйрьлегенә, татар әдәбиятын әйдәп баручы кебек иҗади хасиятләренә мөрәҗәгать ителсә, икенчедән, идеологик кысаларга кертелеп, иҗтимагый-сәяси идеяләр белән генә яшәгән әдәбият үзе тәнкыйтьләнә башлый. Шушы нигездә, әдәбият-сәнгатьнең бурыч-максатлары, үзәк сыйфатлары, әхлаклылыгы мәсьәләләре күтәрелә, Тукай шәхесенең һәм иҗатының яңа буын шагыйрьләргә йогынтысы, каләмгә тотынган кешенең намусы, әдәбиятның хакыйкатьне әйтеп бирү көче хакында тулы бер сөйләшү башларга мөмкинлек туа. Милли үсешкә югары мәдәният аша ирешеп булуы ассызыкланып, шагыйрь иҗаты ярдәмче үрнәк модельгә әверелә.

Бу тенденция С.Хәким иҗатында да көчле. Аның иҗатында («Тукай дәфтәреннән» шигырьләр циклы (1973), «Яңа шигырьләр циклыннан» (1976) һ.б.) Тукайны сурәтләүнең тагын бер сукмагы – шагыйрьне татар халкының юлбашчысы, остазы, әдәбиятны әйдәп баручы итеп сурәтләү үзенчәлеге калкулана.

Х.Туфан Тукай турындагы шигъриятькә тагын бер яңалык алып килә. Милләтнең Тукайга мөнәсәбәте, шуның аша татар халкының бүгенгесе һәм киләчәге хакында уйлану, җәмгыять хәле белән бәйле иҗтимагый тәнкыйть урын ала башлый. Әлеге тенденция Х.Туфанның «Чәчәкләр китерегез Тукайга» (1966) әсәрендә аваз сала:

*Без чәчәкләр аша тапшырырга,*
*Тиеш тә бит сиңа сәламне.*
*Ел буена тик бер генә тапкыр*
*Күрәсең син, Тукай, аларны* [22: 128].

Тукайга хөрмәт, игътибар милләтнең рухи үсешен, мәдәни дәрәҗәсен күрсәтү бизмәненә әйләнә. Х.Туфан «йокыга талган», «көнлекчеләр» тормышы белән яшәүче милләтен шул рәвешле уятырга омтылып, илнең бишьеллык планнарны, гигант төзелешләрне генә мәдхия, максат иткән

сәясәтенә үз карашын җиткерә. Бу күренеш әдәби катламның сәяси юнәлеш алуын күрсәтә һәм соңрак – XX гасырның соңгы чирегендә – аеруча актуальләшә.

Туфан, Хәкимнәрдән соң килгән буын – Р.Фәйзуллин, Р.Мингалим, К.Сибгатуллин, М.Шабаев, Г.Афзал һ.б. – шигырьләрендә иҗтимагый-әдәби катламның әдәбилек ягы калкулана: Тукай образы әдәбиятның сыйфатын билгеләүче бизмән, Шагыйрь дигән бөек исемне йөртергә лаеклылыкны аңлатучы чисталык, аклык-сафлык, намуслылык үрнәге кебек сурәтләнә. Сүз сәнгатенең югары дәрәҗәсе Тукай иҗаты белән билгеләнә, XX йөз башы традицияләрен калкуландырып, әдәбият-сәнгатьнең үсеш дәрәҗәсен танып-белүнең «Тукай иҗаты» дип аталган биеклеге бәяләү бизмәне буларак алына. Иҗтимагый бәя-фикер, әкренләп, әдәбиятның халык тормышындагы ролен күрсәтүгә күчә. Мәсәлән, Р.Фәйзуллинның «Яздан аерып булмый Тукайны!» (1966) шигырендәге строфадан строфага алмашына барган символлар аша чагылган идея, фикер Тукайны һәм аның турындагы поэзияне яңа сыйфатлар белән баета. Яз образының символик катламнары төрле мәгънәви бөтенлекне аерып куярга мөмкинлек бирә.

*Яздан аерып булмый Тукайны!*
*Язда килгән, язда ул янган.*
*Язы, киләчәге барлар ничек китсен,*
*Ничек югалалсын дөньядан?!* [23: 94]

Бер яктан, шигырь тукымасында галәм киңлегендә барган мәңгелек табигый алмашыну – язның кабатлануы – шагыйрьнең мәңгелеген символлаштыра. Икенче яктан, Тукай күңелендәге өмет, хыял, гүзәл гамьнәрне туплаган яз символы, күңел аклыгын, сафлыгын яктырту (яз белән кара елларның янәшәлеге аны үзгә дәрәҗәгә күтәрә) белән бергә, Тукайның яшьлегенә, изгелегенә, мәңгелегенә дә ишарә ясый.

К.Сибгатуллинның җан фәлсәфәсенә нигезләнгән «Яшь белән дә, җан һәм тән белән дә...» шигырендә заман шаукымында керләнгән күңел / Тукай җанының аклыгы каршылыгы соңгысының намус, әхлак, вөҗдан дәрәҗәсен ассызыкларга мөмкинлек бирә. Тукай намусы кешенең җанын сафландыручы, рухын саклаучы сыйфатында кешелеккә бизмән, әхлакый бәянең иң югары ноктасы, әхлакый камиллек һәм халыкка хезмәт үрнәге итеп куела. Шул рәвешле, шагыйрь үз чорына һәм халкына бәя бирә, шуның аша милләт хәленнән ризасызлыгын белдерүче сәяси фикер-карашларын да җиткерә. Ш.Галиевның «Туры Тукай» шигырендә дә шагыйрь – әхлакый камиллек, намус һәм туры сүз символы.

1990 еллардан, XX йөз башы әдәби традицияләрен яңартып, Тукайны шагыйрьләр идеалына хас сыйфатлар берлеге итеп караудан милли көрәшче яки пәйгамбәр югарылыгында тасвирлауга борылыш күзәтелә. И.Юзеевның «Олы җанлы шагыйрь – әдипләргә» (1996), Ш.Галиевның «Туган телнең туган көне» (1995), Зөлфәтнең «Ялгызлык» (1990), Р.Әхмәтҗановның «Тукайның соңгы рәсеме» (1990), Роб.Әхмәтҗановның «Тукай катламы» (2000), Р.Харисның Тукайдан алган «Китмибез без, безгә анда...» эпиграфы белән башланып киткән «Китмибез!» (1990), М.Әгъләмовның «Әйтте Тукай» (1990), Р.Зәйдулланың «Йокысызлык» (1990) һ.б. шигырьләрдә исә, гомумән, милләт язмышы, актуаль мәсьәлә кебек куелып, Тукай шәхесе, аңа мөнәсәбәт милли бәйсезлеккә чакыру мотивлары белән байый, мондый шигырьләрдә символик сурәтлелек, икенчел эчтәлек тудыру күренеше көчле. Мәсәлән, Зөлфәтнең «Ялгызлык» (1990) шигырендә җил, боз образлары чор вазгыятен күз алдына бастыра, идеологик кануннарны танырга ярдәм итә торган мистик кара шәүлә образы милләт тормышын җимерүче көчләрне символлаштыра. Яшәү һәм мәхәббәтне символлаштырган шәм уты Тукайның халкы өчен яшәвен ассызыклый. Зөлфәт даһилар кадерен белмәүнең өзлексез дәвам итүенә ачына һәм мондый сыйфатны милләткә бәя бирүгә юнәлтә.

Мифологик, дини-космогоник образлар системасы М.Әгъләмов, Рәш.Әхмәтҗанов, Л.Зөлкәрнәев, Г.Морат кебек шагыйрьләргә үз иҗатларында Тукайны милли герой, Аллаһ Тәгалә тарафыннан татар милләтенә төшерелгән илче кебек тасвирларга мөмкинлек бирә [24: 128]. Мәсәлән, Г.Моратның «Тукай» (1991) шигырендә Тукай поэзиянең генә түгел, кешелекнең күкләр белән бәйле кәгъбәсенә, табыну үзәгенә күтәрелә. Бу сурәт Р.Гаташта да җанландырыла. Аның «Шигърият!..» (1996) әсәрендә кеше – Аллаһ, Аллаһ – кеше кебек суфичылык мотивы шагыйрьнең бөеклеген раслаучы фәлсәфә белән үрелә. Шигъриятнең бүгенгесеннән риза булмаган, сүз сәнгатенең дәрәҗәсе төшүгә борчылган лирик герой вөҗданы какшаган шигърият һәм каләм әһелләренә Тукайны намус, аклык символы итеп күрсәтә. Шул рәвешле, Р.Гаташ

сәнгатьнең сафлыгы, әдәбият әһеленең намуслылыгы турындагы традицияләрне яңарта. Тукайга мондый бәя Х.Әюповның «Иман яңарту» (1991) шигырендә ачык чагыла.

XX гасырның икенче яртысында иҗат ителгән поэмалар Тукай образын сурәтләүне эпик әсәр мөмкинлекләрен файдаланып тирәнәйтә [25: 118]. С.Хәкимнең «Кырыгынчы бүлмә» (1971), М.Әгъләмовның «Тукайдан хатлар» (1986), Р.Харисның «Тукайның мәхәббәт төшләре» (2000) поэмаларында биографик-реалистик, сатирик-тәнкыйди яңгыраш, иҗтимагый фикерләр (милләт, аның язмышы, үткәне, бүгенгесе, киләчәге); фәлсәфи уйланулар (кеше һәм яшәеш, яшәү мәгънәсе һәм кешелек алдындагы бурыч); әдәби мәсьәләләр (әдәбият һәм аның кеше, милләт тормышындагы роле, әдәбиятның шагыйрьгә йөкләтелгән олы вазифасы, шагыйрь шәхесе); сәяси ачыну (марксистик идеология һәм система китергән фаҗигаләр хакында сөйләү) үзара үрелеп бара. Гасыр башында дөньяви милли идеал булып мәйданга чыккан Тукай образын татар поэзиясе 1960-80 елларда сәяси-реалистик, иҗтимагый, әдәби-аксиологик, хыялый-романтик аспектларда баета һәм 1990 елларда, татар милли күтәрелеше күзәтелгән бер вакытта, кабат милли көрәшче дәрәҗәсендә укучыга тәкъдим итә.

Әнә шулай XX йөз башында милли идеал булып күтәрелгән Тукай шәхесе һәм образы, узган гасырның буеннан-буена үстерелеп, тормыш-яшәешнең күп проблемаларын, татар әдәбиятын борчыган, кызыксындырган барлык сорауларны чагылдыруга хезмәт итә. Гомумән, Тукай турындагы шигърият XX гасыр әдәби-эстетик фикерендә барган үзгәреш-яңарышларны тагын бер кат шәрехләп бара, әдәби традицияләрнең дәвам ителешен, үстерелешен, мәгънәви баетылышын дәлилли һәм сүз сәнгатенең милли нигезләрне, кыйммәтләрне югалтмавы хакында сөйли.

**Әдәбият**


1. *Хәсәнов М.Х.* Тукай турында сүз // Тукай һәм XX гасыр татар мәдәнияте: Шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган халыкара конференция материаллары. Казан, 1997. Б. 3-5.
2. *Заһидуллина Д.Ф.* Әдәбият кануннары һәм заман. Казан: Татар. кит. нәшр., 2000. 271 б.
3. *Хабутдинов А.Ю.* Татарское общественно-политическое движение в досоветский период: 1900-1918 гг. Ч. 1. Казань: Изд-во КГУ, 1997. 62 с.
4. *Акчура Й.* Дамелла Галимҗан әл-Баруди. Казан: «Иман»,1997. 76 б.
5. *Хабутдинова М.М.* Проблема личности в творчестве Х.Такташа: дисс. ...канд. филол. н. Казань, 1998. 181 с.
6. *Зәбирев Г.* «Яшь йөрәкләр» китабы мөнәсәбәте илә // Шура. 1913. №10. Б. 312-313.
7. *Ибрагим Т.* Суфийская концепция «совершенного человека» // Человек как философская проблема: Восток-Запад. М., 1991. С. 63-68.
8. *Сибгатуллина Ә.Т.* Суфичылык серләре: төрки-татар шигъриятендә дини-суфичыл символлар, образлар атамалар. Казан: Заман, 1998. 367 б.
9. *Брагинский И.* К итогам дискуссии о периодизации истории литератур Востока // Народы Азии и Африки. 1965. №3. С. 55-72.
10. *Гафиятуллина Н.М.* XX гасыр татар шигъриятендә Тукай образы: Филол. фән. канд. дисс. Казан, 2002. 173 б.
11. *Синеокая Ю.* Рубеж веков: Русская судьба сверхчеловека Ницше // Ф.Ницше и философия России. СПб, 1990. С. 58-72.
12. *Белый А.* Символизм как миропонимание. М.: Республика, 1994. 528 с.
13. *Лотман Ю.* Литература в контексте русской литературы XVIII века Ю.Лотман // О русской литературе. СПб, 1997. С. 118-137.
14. *Ибраһимов Г.* Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз // Әсәрләр: 8 томда. Т. 5. Казан: Тат.кит.нәшр.,1978. Б. 178-200.
15. *Халит Г.* Многоликая лирика. Казань: Татар. кн. изд-во, 1990. 405 с.
16. *Мусабекова Р.Р.* Сагит Сунчелей: судьба и творчество. Казань, 2001. 120 с.
17. *Сүнчәләй С.* Азан // Шәһри Казан. 1993. 26 май.
18. *Исхакый Г.* Тукай мәхәббәте // Мирас. 1992. №4. Б. 82-84.
19. *Вәлиди Җ.* Мөгаллимә // Вакыт. 1915. 10 гыйнвар.
20. *Рәхим Г.* Урта мәктәптә әдәбият укыту турында // Мәгариф. 1924. №5. Б. 280-290.
21. *Заһидулина Д.Ф.* Татар әдәбиятына хас милли үзенчәлекләр: икенче эчтәлек тудыру // TATARICA. 2013. № 1. Б. 115-126.
22. *Туфан Х.* Чәчәкләр китерегез Тукайга // Мин Тукайга киләм. Казан: Татар.кит.нәшр., 1996. Б. 24-25.
23. *Фәйзуллин Р.* Яздан аерып булмый Тукайны!.. // Мин Тукайга киләм. Казан: Татар.кит.нәшр., 1996. Б. 94-95.
24. *Галиуллин Т.Н., Юсупова Н.М.* Образ Тукая как национальный идеал в татарской поэзии XX века // Филология и культура. Philology and Culture. 2012. №3 (29). С. 126-129.
25. *Гафиятуллина Н.М.* XX гасыр татар шигъриятендә Тукай: Монография. Казан: «Матбугат йорты» нәшр., 2002. 152 б.

# ОБРАЗ ТУКАЯ В ТАТАРСКОЙ ПОЭЗИИ XX ВЕКА: ЛИТЕРАТУРНО-ЭСТЕТИЧЕСКАЯ И ОБЩЕСТВЕННО-ФИЛОСОФСКАЯ ЛИНИИ ИНТЕРПРЕТАЦИИ

**Нурфия Марсовна Юсупова,**
Казанский федеральный университет,
Россия, 420021, г. Казань, ул. Татарстана, д. 2,
faikovich@mail.ru.

В истории каждого народа есть личности, жизнь и деятельность которых, несмотря на социально-политические катаклизмы в обществе, сохраняют в памяти и сознании поколений образ национального героя. Наследием и жизнедеятельностью таких личностей оценивается вклад каждого народа в мировую культуру. В этом смысле они являются не только талантливыми сыновьями своего народа, но и представителями конкретной национальной культуры, из которой и формируется мировая цивилизация. Габдулла Тукай является такой личностью, которая в силу своей культурной значимости получила статус национального идеала.

Поэзия о Тукае в татарском словесном искусстве формируется в начале XX века. В татарской литературе начала XX века произошла трансформация общественно-философской и литературно-эстетической мысли, результатом которой стало возникновение новой концепции идеала: образ Тукая идеализируется как национальный хадим. В поэтической интерпретации национального идеала соприкасаются традиции концепции «Камиль инсан» и теории сверхчеловека Ф.Ницше. В данном ключе в стихотворениях Ш.Бабича, М.Файзи, С.Сунчелея, Н.Габидова и др. образ Тукая интерпретируется как «национальный хадим» и пророк, обладающий нравственной чистотой, глубиной духа, богатством чувств и души и в то же время способный объединить татарскую нацию. Вознесение образа поэта на уровень пророка усиливает общественный авторитет литературы в целом, статус поэта начинает восприниматься как один из самых важных и полезных для нации видов деятельности.

В 1920-1930-е годы в связи с утверждением марксистского литературоведения происходит социологизация образа Тукая: в стихотворениях Г.Хужи, А.Юныса, Ш.Маннура на первое место выходит образ Тукая как общественного деятеля за счет «оттеснения» Тукая-поэта, Тукая-художника, поэт получает интерпретацию борца за свободу угнетенных классов, патриота.

Трансформацию образа Тукая в татарской поэзии второй половины XX века вызывают новации в общественно-философской, литературно-эстетической мысли и демократические тенденции в общественном развитии. В стихотворениях Х.Туфана, С.Хакима, Р.Файзуллина, Р.Мингалима, К.Сибгатуллина, Г.Афзала наблюдается новый подход: отказ от социологизации образа и объединение национального и эстетического ракурсов, чувствуется тенденция к сакрализации личности поэта, образ Тукая служит мерилом подлинной поэзии, образцом совершенной нравственности, претендующим на высокое звание поэта.

В последней четверти XX века литературно-художественная мысль отводит огромную роль литературе в жизни народа. В стихотворениях М.Аглямова, Раш.Ахметзянова, Зульфата, Р.Хариса, Г.Мурат и др. Тукай изображается как борец за национальные идеалы. Мифологическая, религиозная, космологическая образность в художественных системах служит для изображения Тукая как национального героя, посланника Аллаха татарскому народу.

**Ключевые слова**: татарская поэзия, идеал, Тукай, Совершенный человек, образ, интерпретация, концепция героя.